**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 март № 193

г. Казань

Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бу карар кабул ителгән көннән ике атна эчендә хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларның субсидияләр бирү турындагы гаризаларын карау комиссиясе хакында нигезләмә эшләргә һәм комиссия составын расларга;

Тәртипне куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\193.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 28 март, 193 нче
карары белән расланды

**Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) тормышка ашыру кысаларында хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны (алга таба – проектлар) тормышка ашыруга социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – социаль юнәлештәге оешмалар) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели.

Проектлар, түбәндәгеләрне үткәрүне кертеп, хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыруга йөз тотарга тиеш:

чит ил гражданнарының бу категориясе һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында планлы санитария-агарту эшләрен;

йогышлы авыруларны профилактикалау буенча белемнәр дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) субсидияләрне социаль юнәлештәге оешмаларга проектларны тормышка ашыруга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге оешмаларның гаризаларын карау буенча Министрлык тарафыннан махсус төзелгән комиссия (алга таба – Комиссия) карары нигезендә бирә.

Комиссияне Министрлык хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү чараларын тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (килешү буенча), иҗтимагый оешмалар (килешү буенча) вәкилләреннән төзи.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган юридик зат булган социаль юнәлештәге оешмаларга бирелә.

## II. Субсидия бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия бирүнең максаты, түбәндәгеләрне үткәрүне кертеп, хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыру:

чит ил гражданнарының бу категориясе һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында планлы санитария-агарту эшен;

йогышлы авыруларны профилактикалау буенча белемнәр дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар.

5. Субсидия бирү өчен социаль юнәлештәге оешмаларны бәяләү критерийлары:

узган финанс елы ахырына социаль юнәлештәге оешмаларны юридик зат буларак дәүләт теркәвенә алу вакыты кимендә биш календарь елы булырга тиеш;

социаль юнәлештәге оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге һәм социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлеге устав нигезендә соңгы биш календарь елы эчендә гамәлгә ашырылырга тиеш;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаска тиеш;

социаль юнәлештәге оешмаларның хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча кимендә биш еллык эш тәҗрибәсе булырга тиеш;

социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү, хезмәт мигрантларына социаль, профилактика хезмәтләре һәм башка хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары һәм (яки) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән хезмәттәшлек гамәлгә ашырырга тиеш;

медицина, социаль эш, белем бирү, психология өлкәсендә профильле белемнәре булган һәм хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау буенча эш тәҗрибәсе булган квалификацияле белгечләр тарафыннан проектны тормышка ашыру тәэмин ителергә тиеш;

социаль юнәлештәге оешмаларның эшләнгән һәм бастырып чыгарылган, хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау эшчәнлегенә караган рецензияләнә торган фәнни журналларда бастырып чыгарылган кимендә ун исемдәге фәнни басмалары, мәгълүмати һәм методик материаллары булырга тиеш;

тормышка ашырырга планлаштырыла торган проект түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

хезмәт мигрантларына юнәлеш бирә торган кереш курслар өчен уку-укыту-методик комплект эшләүне, апробацияләүне, кулланышка кертүне тәэмин итү;

хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар үткәрү;

проектны тормышка ашырганда кимендә 1 200 хезмәт мигрантын җәлеп итүне тәэмин итү;

проектны тормышка ашыру вакыты – 6 айдан 12 айга кадәр. Моның белән бергә, проектны тормышка ашырып бетерү вакыты субсидия бирелгән елдан соң килүче елның 1 октябреннән дә соң булмаска тиеш.

6. Социаль юнәлештәге оешмаларга бирелә торган субсидия күләме тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында Дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү һәм хезмәт миграциясен җайга салу чараларын тормышка ашыру» ярдәмче программасы белән «Хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыру» чарасын тормышка ашыру өчен күздә тотылган акча чикләрендә билгеләнә.

Әгәр проектны тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге оешма сораган финанс чаралары суммасы тиешле финанс елына Дәүләт программасы белән «Хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыру» чарасын тормышка ашыруга күздә тотылган финанс чаралары суммасына тигез яки аннан артык булса, субсидия тиешле финанс елына Дәүләт программасы белән «Хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыру» чарасын тормышка ашыру өчен күздә тотылган акча күләмендә бирелә.

Әгәр проектны тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге оешма сораган финанс чаралары суммасы тиешле финанс елына Дәүләт программасы белән «Хезмәт мигрантлары өчен юнәлеш бирә торган кереш курслар оештыру» чарасын тормышка ашыру өчен күздә тотылган финанс чаралары суммасыннан кимрәк булса, субсидия социаль юнәлештәге оешма сораган акча күләмендә бирелә, ә файдаланылмый калган финанс чаралары Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

7. Субсидияләр бетерелү, үзгәртеп оештырылу, бөлгенлеккә төшү процедураларын үтә торган, шулай ук эшчәнлекләре законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатылып торган социаль юнәлештәге оешмаларга бирелми.

8. Субсидия алу өчен Комиссиягә, түбәндәгеләрне теркәп, Министрлык раслый торган форма буенча субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза) кертелә:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза биргән датага иң күбе бер ай алдан алынган чыгарма;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга кертелгән барлык гамәлдәге үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең күчермәләрен;

социаль юнәлештәге оешмаларның соңгы биш календарь елы эчендә финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруын раслый торган документлар күчермәләрен: салым органының кабул итү турындагы билгесе белән билгеләнгән формалар буенча табышлар һәм зыяннар турында хисаплар һәм еллык бухгалтерлык баланслары; законнар нигезендә салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы социаль юнәлештәге оешмалар гаризага 2013 елдан башланган чор өчен салым органының кабул итү турындагы билгесе белән әлеге бухгалтерлык хисаплылыгы күчермәләрен, шулай ук билгеләнгән форма буенча салым органының кабул итү турындагы билгесе белән салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә түләнә торган салым буенча еллык салым декларацияләре күчермәләрен терки;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмауны раслый торган салым органы белешмә кәгазен;

соңгы биш календарь елында социаль юнәлештәге оешмаларның хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтүе, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау буенча эш алып баруы карала торган шартнамәләр һәм (яки) дәүләт контрактлары күчермәләрен (бу шартнамәләрнең һәм/яки дәүләт контрактларының үтәлүен раслый торган документлар күчермәләрен теркәп);

социаль юнәлештәге оешмаларның хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча кимендә биш еллык эш тәҗрибәсе булуны тасвирлаган аңлатма язуын;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары һәм (яки) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү, хезмәт мигрантларына социаль, профилактика һәм башка хезмәтләр күрсәтү буенча хезмәттәшлек итү турындагы килешүләре күчермәләрен;

социаль юнәлештәге оешмаларның кадрлар составы, белгечләренең белемнәре һәм эш тәҗрибәсе турында мәгълүмат;

авторлыгы социаль юнәлештәге оешмалар коллективыныкы яки социаль юнәлештәге оешмаларның аерым хезмәткәрләренеке булган бастырып чыгарылган һәм нәшер ителгән мәгълүмати һәм методик материаллар, хезмәт мигрантларына мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм кешеләрнең үз-үзләрен социаль тискәре тотуын профилактикалау эшчәнлегенә караган рецензияләнә торган фәнни журналларда бастырып чыгарылган фәнни басмаларның күчермәләрен;

социаль юнәлештәге оешмалар вәкиленең гаризага кул кую вәкаләтләрен раслый торган документ;

проектның проблемасын, максатларын һәм бурычларын, төп чараларын, көтелә торган нәтиҗәләрен тасвирлауны үз эченә алган проектны, шулай ук проектны тормышка ашыру буенча календарь планын, проектның акчаны тоту юнәлешләре һәм күләмнәре (финанслау күләмнәре) карала торган бюджетын;

теркәлә торган барлык документларның исемен үз эченә алган теркәлгән документлар исемлеген.

9. Социаль юнәлештәге оешмалар үз инициативалары буенча Комиссиягә дәүләт органнарының һәм оешмаларның хезмәт мигрантларына социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү, социаль, профилактика хезмәтләре һәм башка хезмәтләр күрсәтү буенча социаль юнәлештәге оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү турындагы бәяләмәләрен кертергә хокуклы. Социаль юнәлештәге оешмалар бу бәяләмәләрне кертмәгән очракта, Министрлык социаль юнәлештәге оешмалар керткән үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүләрдә күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан һәм оешмаларыннан һәм (яки) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан үзара хезмәттәшлек итү турында бәяләмәләр соратып ала.

10. Гаризаларны кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү вакытлары Министрлык боерыгы белән билгеләнә. Әлеге мәгълүмат гаризаларны кабул итә башлаган көнгә кимендә 10 көн кала Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## III. Гаризалар кабул итү һәм карау

11. Комиссия социаль юнәлештәге оешмаларга субсидия бирү өчен проектларны бу Тәртипкә һәм Комиссия турындагы нигезләмәгә таянып кабул итә, карый, бәяли һәм сайлап ала.

12. Комиссия теркәлгән документлар белән бергә гаризаларны кабул итә һәм аларны кергән көннәреннән бер эш көне эчендә терки.

13. Гаризаларны карау һәм бәяләү Комиссия тарафыннан гаризалар кабул итеп бетерелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

14. Комиссия, бу Тәртипнең 3 – 5 нче һәм 8 нче пунктларында бәян ителгән шартларны һәм таләпләрне исәпкә алып, социаль юнәлештәге оешмалар проектларын карауны, бәяләүне һәм аларны сайлап алуны гамәлгә ашыра.

15. Гариза, әгәр дә ул бу Тәртипнең 8 нче пунктында бәян ителгән таләпләргә туры килсә, ә гариза тапшырган социаль юнәлештәге оешмалар аңа карата бу Тәртиптә куела торган таләпләргә җавап бирсә, тиешенчә дип таныла.

Комиссия гаризаны түбәндәге очракларда кире кага, әгәр:

гариза тапшырган социаль юнәлештәге оешма үзенә карата бу Тәртиптә куела торган таләпләргә туры килмәсә;

гариза бу Тәртип таләпләренә туры килмәсә;

гаризада һәм аңа теркәлгән документларда дөрес булмаган мәгълүмат булса.

16. Комиссия гаризаны кире кагу турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә Министрлык бу турыда, нигезләрен күрсәтеп, социаль юнәлештәге оешмаларга язма хәбәрнамә җибәрә.

17. Комиссия бу Тәртиптәге шартларга һәм таләпләргә туры килү-килмәү буенча кире кагылмаган проектларны сайлап алуны һәм гаризаларны бәяләүне гамәлгә ашыра.

Комиссия баллар системасы буенча һәр гаризаның рейтингын билгели. Иң зур йомгаклау рейтингы җыйган гаризага беренче сан куела. Гаризаларның тәртип саннарын алга таба бүлү йомгаклау рейтингы кими бару тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Һәр гариза Комиссиянең һәр әгъзасы тарафыннан аерым баллар системасы буенча бу Тәртипнең 5 нче пунктында бәян ителгән һәр критерий буенча бәяләнә. Критерийларның һәркайсы 1 баллдан 10 баллга кадәр бәяләнә. Аерым критерий буенча һәр гаризаның йомгаклау баллы бу критерий буенча комиссиянең барлык әгъзалары куйган бөтен баллар бәяләренең уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә. Һәр гаризаның гомуми йомгаклау рейтингы барлык критерийлар буенча бу гаризаның йомгаклау баллары суммасы буларак билгеләнә.

Берничә гаризаның йомгаклау рейтинглары бер үк төрле булса, кечерәк тәртип саны башкалардан алданрак кергән гаризага бирелә.

18. Комиссия субсидия бирү турындагы карарны гаризасына беренче сан куелган социаль юнәлештәге оешмага карата кабул итә. Башка социаль юнәлештәге оешмаларга субсидия бирелми.

Гаризасына беренче тәртип саны куелган социаль юнәлештәге оешма Министрлык белән субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзүдән баш тарткан очракта, Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә гаризасына икенче сан куелган социаль юнәлештәге оешмага субсидия бирү хакында карар кабул итә.

Комиссия кабул иткән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамә Министрлык тарафыннан социаль юнәлештәге оешмага Комиссия тиешле карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә язма рәвештә җибәрелә. Кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

19. Субсидия бирү Комиссия субсидия бирү турында карар кабул иткән социаль юнәлештәге оешма һәм Министрлык арасында төзелә торган субсидия бирү хакындагы шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла. Шартнамә Комиссия субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә төзелә. Шартнамәнең формасы, шулай ук вакытлары һәм аның бу Тәртиптә билгеләнмәгән башка шартлары Министрлык тарафыннан билгеләнә.

Шартнамәдә субсидияне бирү һәм күчерү тәртибе, вакытлары, субсидиядән файдалану турында хисап кертү тәртибе һәм формасы, субсидияне аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта кире кайтару тәртибе, субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару тәртибе һәм очраклары, субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә, субсидия алучының бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәвенә Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла.

Министрлыкның субсидияне күчерүе әлеге максатларга күздә тотылган акча Министрлык исәбенә кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә шартнамә нигезендә субсидия алучының хисап исәбенә гамәлгә ашырыла.

20. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

21. Субсидия алучы субсидияне Министрлыкның түбәндәге очракларда бирә торган тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирергә тиеш:

субсидия алучы субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керткәндә;

Бу Тәртиптә һәм шартнамәдә күздә тотылган субсидия бирү шартлары үтәлмәгәндә.

22. Субсидия алучы субсидияне кире кайтару вакытын бозса, Министрлык бу Тәртипнең 21 нче пунктындагы беренче абзацта билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе һәм

Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелергә тиеш.

23. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

24. Субсидияләрдән максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---